КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 ноябрь г.Казань № 994

Әлмәт муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Охтин-Ойл» ябык акционерлар җәмгыятенең Әлмәт муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 0,9724 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:07:160004:489 кадастр саны белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермәләрдә күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин